# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 23 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылында гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә 1 төркем инвалидлар, көндезге уку йортлары студентлар, дүрт һәм аннан да күбрәк бала белән күп балалы гаиләләр, хөкем ителгәннәр, Украина территориясендә махсус хәрби операция катнашучылар һәм гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. махсус техниканы тоту трактор Беларус-82.1 (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, йөртүче хезмәтенә түләү);
2. Зур Нөркәй авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм техник хезмәт күрсәтү);
3. Зур Нуркәй авылында җәйге вакытта территорияне чабып тору (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ;
4. Зур Нөркәй авылында зиратлар территориясен әйләндереп алу (төзелеш материаллары сатып алу, ,зиратлар территориясен эйләндерү (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
5. Зур Нуркәй авылы зиратларында агачларны кисү;
6. Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарның вакытлыча туплану урыннарын җыештыру (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү).

2. Әлеге карарны Зур Нөркәй авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми

йтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында ttp://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

арман муниципаль районы
үр Нөркәй авыл җирлеге башлыгы,
ражданнар җыенында рәислек итүче А.В.Мустафина